| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2018 Казан ш. № 10-109/кс

«Мехуборка К» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 – 2021 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифлар билгеләү турында

"Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында" 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең "Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Мехуборка К" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифларны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Мехуборка К» жаваплылыгы чиклэнгэн җәмгыяте өчен 2019 – 2021 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрларын әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

3. "Мехуборка К" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына

тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча ачарга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 30 ноябрендәге 10-109/кс
номерлы карарына 1 нче кушымта

«Мехуборка К» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә
2019 – 2021 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, чик тарифлар

| т/б № | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең, оешманың исеме | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифлар, сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | "Мехуборка К" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 93,45 | 110,11 | 110,11 | 119,40 | 119,40 | 139,83 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 30 ноябрендәге 10-109/кс
номерлы карарына 2 нче кушымта

«Мехуборка К» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 – 2021 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | "Мехуборка К" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2019 | 2040,04 | 1 | - | - |
| | | 2020 | 2088,30 | 1 | - | - |
| | | 2021 | 2150,12 | 1 | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге